ЧӘРШӘМБЕ
20 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 16 (6738)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ,

Соңгы сәгатьтә

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР КӨНЬЯКТА ВАЛУЙКИ, УРАЗОВО, КАМЕНСК, ПЕТРОВСКОЕ ШӘҺӘРЛӘРЕН, БЕЛАЯ КАЛИТВА ТИМЕР ЮЛ СТАНЦИЯСЕН АЛДЫЛАР.

1. 19 нчы январьда ВОРОНЕЖ ФРОНТЫ гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерә барып, ВАЛУЙКИ шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, УРАЗОВО шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

Дошманның КАМЕНКА—РОССОШЬ тимер юл линиясеннән көнчыгыштарак булган гаскәрләре безнең гаскәрләр тарафыннан тулысынча чолгап алындылар һәм юк ителәләр.

19 нчы январьда кичкә таба плен алынган солдатлар һәм офицерлар саны 21.000 гә артты. Шулай итеп, Воронеж фронты районында пленныйлар саны 52.000 кешегә житте, шуларның 27.500 е венгерлар, 22.000 е итальяннар һәм 2.500 е немецлар.

13 нче январьдан 18 нә кадәр булган сугышлар вакытында Воронеж фронты гаскәрләре тарафыннан түбәндәге трофейлар КУЛГА ТӨШЕРЕЛДЕ: 170 танк, 1.700 орудие, 2.800 пулемет, 4.000 миномет, 6.000 автомашина, 1.500 ат, 55.000 винтовка, 10 миллионга якын патрон, 600.000 снаряд, 150 дән артык төрле складлар.

2. КӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ФРОНТ гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә, 19 нчы январьда КАМЕНСК шәһәрен, шулай ук район үзәге һәм зур тимер юл станциясе БЕЛАЯ КАЛИТВАНЫ алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде, аларның исәбе алына.

3. ТӨНЬЯК КАВКАЗДА безнең гаскәрләр ПЕТРОВСКОЕ шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Иптәш А. М. Василевскийга Армия генералы исемен бирү турында

ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ КАРАРЫ

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы карар бирә: Александр Михайлович Василевскийга СССР Верховный Советы Президиумының 1940 нчы ел 7 нче май Указы белән билгеләнгән Армия Генералы исемен бирергә.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе И. СТАЛИН.
СССР Совнаркомы эшләрен идарә итүче Я. ЧАДАЕВ.

18 январь. 1943 ел.
Москва, Кремль.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы янында җирле ягулык промышленносте идарәсе төзү турында

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Халык Комиссарлары Советы янында җирле ягулык промышленносте идарәсе төзәргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре С. СӘЕТГӘРӘЕВ.

Казан, Кремль.
18 январь, 1943 ел.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

Иптәш К. А. Бабанинны Татарстан АССР Совнаркомы янындагы ягулык промышленносте идарәсенең начальнигы итеп билгеләү турында

Константин Александрович Бабанин иптәшне Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Халык Комиссарлары Советы янындагы җирле ягулык промышленносте идарәсенең начальнигы итеп билгеләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре С. СӘЕТГӘРӘЕВ.

Казан, Кремль.
18 январь, 1943 ел.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

19 нчы ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

19 нчы январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинград** районында, **Воронеждан көньяктарак**, **Төньяк Кавказда, Донның** түбәнге агымы, **Төньяк Донец** районында һәм Ладога күленнән көньяктарак элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр чолганып алынган немец-фашист гаскәрләрне кыруны дәвам иттерделәр. Төньяк-көнбатыштан хәрәкәт итүче Н-че часть сугыша-сугыша алга барды һәм 600 гә якын гитлерчыны юк итте. Немецларның 316 солдаты һәм офицеры плен алынды. Бер участокта немецлар кире чигенгән вакытта алты көпшәле минометлар белән көчле заслон калдырганнар иде. Лейтенант Кышин җитәкчелегендәге безнең сугышчыларның бер группасы дошманның тылына үтеп керде, гитлерчыларны үтереп бетерде һәм алтышар көпшәле 6 миномет кулга төшерде.

* * *

Воронеждан көньяктарак совет гаскәрләре уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган бик күп пунктларны алдылар. Бер авылда Н-че часть подразделениелары элемтә узелын һәм дошман армиясе штабының берничә бүлекләрен кулга төшерделәр. Бу авылга килү юлларында һәм аның урамнарында дошманның 500 гә якын солдат һәм офицеры юк ителде. Икенче бер участокта венгерларның бер батальон пехотасы батальон командиры җитәкчелегендә бөтен составы белән пленга бирелде.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Немецлар бер зур тимер юл станциясе районына пехота һәм танкларның шактый күп көчләрен туплаган булганнар. Дошман ныклы оборона белән безнең гаскәрләрнең тагын да алга баруларын тоткарларга маташкан. Н-че часть сугышчылары бу станцияне алу өчен бик каты сугышлар алып баралар. Безнең башка частьларыбыз, дошманның бу терәк пунктын әйләнеп үтеп, һөҗүм сугышлары алып баралар. Икенче бер участокта безнең частьлар дошманның 30 танк һәм 40 орудиесе белән бергә бер мотопехота полкын чолгап алдылар. Дошманның бу группасын юк итү өчен сугышлар бара. Сугышларның барышында гитлерчылар авыр югалтуларга дучар ителделәр.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре Төньяк Донец елгасы аркылы чыгып алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта немецларның бер батальон пехотасы тар-мар ителде. Сугыш кырында дошманның 400 дән артык үле гәүдәсе калды. 6 орудие, 22 пулемет, 28 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар, дошманның бик нык каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган 6 пунктны алдылар. Немецларның 300 солдат һәм офицерлары үтерелде. Халык яши торган бер пунктта безнең подразделениебыз немецларның 20 солдатын плен алды. Пленныйларны авыл буйлап алып барган вакытта, немецларның качып торган солдатлары кулларын югары күтәреп, өйләрдән һәм сарайлардан йөгереп чыга башладылар. 20 пленныйга немецларның тагын 40 солдаты кушылды.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бардылар. Н-че укчы часть каты сугышта дошманның бик каты ныгытылган позицияләрен алды. Немецларның 3 танкысы сафтан чыгарылды һәм яндырылды, 12 автомашинасы һәм сугыш припаслары төялгән 23 олавы юк ителде.

* * *

Гомель өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды ике атна эчендә дошманның 4 тимер юл эшелонын, шул исәптән солдатлар һәм офицерлар төялгән 2 тимер юл составын юлдан чыгарып аударган. Минск өлкәсендәге берничә партизан отрядлары соңгы көннәрдә 5 тимер юл күперен һәм шоссе юлларындагы 27 күперне шартлатканнар. Совет патриотлары шулай ук 4 полиция участогын һәм фашистларның волость управлениесен тар-мар иткәннәр.

* * *

Түбәндә Сталинград өлкәсенең Нижне-Чирская станицасында немец-фашист кабахәтләрнең ерткычлыклары турында акт игълан ителә: «Немец ерткычлар безнең станицада барлык культура учреждениеләрен таладылар һәм җимерделәр. Бандитлар башлангыч һәм тулы булмаган урта мәктәпләрне, авыл хуҗалыгы техникумын, комбайнчылар мәктәбен, авыл хуҗалыгы мәктәбен һәм музейны тар-мар иттеләр. Гитлерчылар укытучылардан Полина Перетертованы, Елена Пономареваны, Тамара Артемьеваны, комбайнчылар мәктәбе директоры Лебедевны һәм башкаларны атып үтерделәр, ә исән калган укытучыларны солдат кухняларында һәм ныгытмалар төзелешендә эшләргә, чокырлар казырга, бетле фрицларның бельеларын юарга, кухняларга утын, су ташырга мәҗбүр иттеләр һ. б. Фашист кеше ашаучылар төнлә белән балалар йортына бәреп керделәр һәм балалар йортында тәрбияләнүче 4 яшьтән алып 15 яшькә кадәр булган 47 баланы атып үтерделәр» Актка кул куйдылар: А. Сазыкина, А. Звездина, А. Тугарина, А. Сухорукова, К. Дизцова, Л. Тяжелова, Т. Николаева, А. Серегина, А. Белянская, Г. Рябова һәм башкалар.

Ленин көннәре алдыннан

Бөтен дөнья пролетариаты юлбашчысы В. И. Ленинның үлүенә 19 ел тулу уңае белән Казанның хезмәт ияләре арасында беседалар һәм докладлар үткәрелә. Докладчылар өчен ВКП(б) шәһәр комитеты тарафыннан инструктив доклад үткәрелде.

19 нчы январьдан алып 22 сенә кадәр предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә В. И. Ленин истәлегенә багышлап, эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең җыелышлары үткәрелә. Аларда «Ленин байрагы астында» дигән темага докладлар ясала.

ВКП(б) райкомнары янында В. И. Ленин истәлегенә багышланган әдәбият күргәзмәләре ачылды. Казандагы Ленин музей-йортында хезмәт ияләренең экскурсияләре оештырыла.

* * *

В. И. Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының студентлары һәм фәнни работниклары бөтен дөнья хезмәт ияләре юлбашчысы бөек Ленин көннәрен фәнни эшләрне тагын да көчәйтү белән билгеләп үтәләр. Университетта фәнни конференцияләр үткәрелә. Аларда университет аспиранты иптәш Кущев «Комсомол турында Ленин һәм Сталин» дигән темага доклад ясый. Даһи юлбашчының истәлегенә багышлап, студентларның, фәнни работникларның һәм хезмәткәрләрнең гомуми җыелышы үткәрелә. Җыелышта доцент иптәш Окунева «Лениннан башка Ленин юлыннан 19 ел» дигән темага доклад белән чыгачак.

Кокушкино авылына студентларның чаңгы походы оештырыла. Студентлар бу авылда ачылган Ленин музей-йортын караячаклар һәм В. И. Ленин истәлеге турында, халыкара хәл һәм бөек ватан сугышы турында колхозчылар арасында беседалар үткәрәчәкләр.

* * *

Татарстанның фәнни китепханәсендә бөек Ленин истәлегенә багышланган әдәбият күргәзмәсе оештырылды. Күргәзмәгә В. И. Ленин турында рус һәм татар телләрендә язылган күп төрле әдәбият, В. И. Ленинның портретлары һәм төрле рәсемнәр куелды.

Фәнни китепханә бер хәрби частьта Ленин почмагы ачуга булышлык күрсәтте. Аңа В. И. Ленинның әсәрләрен, аның турында язылган күп төрле әдәбият, төрле рәсемнәр һәм башка материаллар җибәрде. Сугышчылар һәм командирлар Ленин почмагындагы әдәбиятны зур кызыксыну белән укыйлар.

ВКП(б) ның Сталинград Өлкә Комитеты секретаре иптәш ПРОХВАТИЛОВКА

«Героик Сталинград» исемле авиаэскадрильялар төзүгә 5 миллион сум җыйган Сталинград өлкәсе колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Н-ЧЕ АРМИЯ
КОРЗУН ҺӘМ КОННОВ ИПТӘШЛӘРГӘ

«Фронтовик» исемле танклар колоннасы төзүгә 4 миллион сум акча җыйган Н-че армиянең сугышчыларына һәм командирларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

ВКП(б) ның ОРЕЛ ӨЛКӘСЕ КОМИТЕТЫ СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ МАТВЕЕВКА

Орел партизаннары исемендәге танклар колоннасы төзелешенә беренче тапкыр керткән 12.000.000 сумнан тыш өстәмә рәвештә 11.500.000 сум акча җыйган, Кызыл Армия фондына өстәмә рәвештә икмәк, ит һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары тапшырган Орел өлкәсе колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына, эшчеләренә һәм хезмәткәрләренә минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

КАРЕЛИЯ ФРОНТЫ ИПТӘШ ФРОЛОВКА, ИПТӘШ БАТРАКОВКА, ИПТӘШ КУПРИЯНОВКА, ИПТӘШ РУМЯНЦЕВКА.

Кызыл Армия өчен кораллар төзүгә 24.254.938 сум акча җыйган Карелия фронтының сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Н-ЧЕ ГВАРДИЯ БЕРЛӘШМӘСЕ ГВАРДИЯ ТАНК ГАСКӘРЛӘРЕ ГЕНЕРАЛ-МАЙОРЫ КАТУКОВКА, ГЕНЕРАЛ-МАЙОР ПЕПЕЛЬГА

Танклар колоннасы төзелешенә 1.500.000 сум акча җыйган Н-че гвардия берләшмәсе сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Н-ЧЕ АРМИЯ ГЕНЕРАЛ-МАЙОР ИПТӘШ КАТКОВКА ПОЛКОВОЙ КОМИССАР ИПТӘШ ТИТОВКА

Н-че Урал армиясе исемендәге танклар колоннасы төзелешенә 4.014.010 сум акча җыйган Н-че армия сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз

И. СТАЛИН.

ВКП(б) ның Смоленск өлкә комитеты секретаре иптәш ПО..ОВКА

Смоленск өлкәсенең немец оккупантлардан азат ителгән районнарының, шулай ук дошман тарафыннан вакытлыча оккупацияләнгән районнарының, илнең оборонасы фондына, шул исәптән «Смоленск партизаны» исемле танклар колоннасы төзүгә 14.952.980 сум акча һәм 6.000 пот ашлык керткән хезмәт ияләренә минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Н-ЧЕ АРМИЯ ПОПОВ, НИКОЛАЕВ, МИХАЛЬЧУК ИПТӘШЛӘРГӘ

«Совет ватаны өчен» исемле танклар колоннасы төзелешенә 9.500.000 сум акча җыйган Н-че армия кызылармеецларына, командирларына һәм политработникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

БРЯНСК ФРОНТЫ РЕЙТЕР, СУСАЙКОВ ИПТӘШЛӘРГӘ

Танк колонналары, самолет эскадрильялары һәм артиллерия батареялары төзелеше өчен 23.572.925 сум акча җыйган Брянск фронты сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

АРХАНГЕЛЬСК ХӘРБИ ОКРУГЫ ГАСКӘРЛӘРЕ КОМАНДУЮЩИЕ ГЕНЕРАЛ-ЛЕЙТЕНАНТ ШЕВАЛДИНГА АРХАНГЕЛЬСК ХӘРБИ ОКРУГЫ ХӘРБИ СОВЕТЫ ЧЛЕНЫ ГЕНЕРАЛ-МАЙОР ЕФИМОВКА АРХАНГЕЛЬСК ХӘРБИ ОКРУГЫ ПОЛИТУПРАВЛЕНИЕСЕ НАЧАЛЬНИГЫ ПОЛКОВНИК ЕРОХИНГА

«Архангельск комсомолецы» исемле самолетлар эскадрильясы, «Архангельск һәм Вологда колхозчысы» исемле һәм фронтовик хатыннары исемендәге танк колонналары төзелешенә 8.088.133 сум акча җыйган Архангельск хәрби округы сугышчыларына, курсантларына, командирларына һәм фронтовик семьяларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Н-ЧЕ АРМИЯ ГЕНЕРАЛ-ЛЕЙТЕНАНТ ИПТӘШ КУРАСОВКА ГЕНЕРАЛ-МАЙОР ИПТӘШ ТЕВЧЕНКОВКА ПОЛКОВНИК ИПТӘШ ШАБАЛИНГА

Кызыл Армия өчен кораллар төзүгә 8.284.000 сум акча җыйган Н-че армия сугышчыларына һәм командирларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Бүләкләнүчеләргә орденнар һ... медальләр тапшыру

Шушы көннәрдә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Динмөхәмәтов СССР Верховный Советы Президиумы Указы буенча бүләкләнгән иптәшләргә орденнар һәм медальләр тапшырды. Югары бүләк алучылар арасында Кызыл Армиянең командирлары, профессорлар, врачлар, инженерлар, эшчеләр һәм башкалар бар.

Бөек ватан сугышы фронтларында немец-фашист басып алучыларга каршы сугышларда зур батырлык күрсәткән, сержант иптәш М. А. Здохловка, боцман иптәш Н. В. Борисовка, кече лейтенант иптәш Д. В. Киселевка Кызыл Йолдыз ордены, капитан иптәш А. Ф. Марчукка Кызыл Байрак ордены тапшырылды.

Хөкүмәт заданиеләрен отлично үтәгән өчен Казан Химия-Технология институты профессоры иптәш Г. Х. Камай һәм кафедра мөдире иптәш С. Н. Ушаков «Почет билгесе» ордены белән, ассистент иптәш А. Т. Гумеров «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән, врач иптәш Ш. Х. Бабекова «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале белән бүләкләнделәр.

Кызыл Армияне һәм Хәрби-Диңгез Флотын продуктлар белән тәэмин итүдә үрнәк булырлык эшләре өчен Вахитов исемендәге жиркомбинатның баш инженеры иптәш Н. Г. Щербаковка, сабын кайнатучы иптәш Л. И. Богодка Кызыл Байрак ордены, шул ук заводның электросварщигы иптәш М. В. Вәлиевага «Почет билгесе» ордены һәм слесарь иптәш Гатауллинга «Хезмәттәге батырлык өчен» медале тапшырылды.

Бүләкләнүче иптәшләр югары бүләк өчен Совет хөкүмәтенә рәхмәт белдерделәр һәм киләчәктә тагын да яхшырак эшләргә сүз бирделәр.

Иптәш Динмөхәмәтов бүләкләнүчеләрне котлап сөйләде һәм аларның киләчәктәге эшләрендә уңышлар теләгәнлеген белдерде.

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ШАРТЛАРЫНДА МӘКТӘПЛӘРДӘ ТӘРБИЯ ЭШЕ

Совет мәктәбе һәм комсомол үзләре тәрбияләп үстергән күп кенә яшьләрнең сугышта күрсәткән батырлыклары белән бик урынлы рәвештә горурланалар: Алар да тәрбияләнеп чыккан меңнәрчә пионерлар һәм комсомолецлар хәзер геройлар булып үстеләр. Казан шәһәренең 91 нче мәктәбе коллективы үзендә тәрбияләнгән Советлар Союзы Герое иптәш Григорьев белән мактанырга хаклы.

Бөек Ватан сугышы мәктәпләрнең эшендә шактый зур кыенлыклар китереп чыгарды. Шуның белән бергә сугыш яшь граждannар арасында гаять көчле патриотик күтәрелеш тудырды. Алар моны эш белән күрсәтәләр.

1942 нче елда колхозларда һәм совхозларда авыл хуҗалыгы эшләрендә Татарстанның 112.000 укучысы һәм 11.000 педагогы катнашты. Алар 4 миллионга якын хезмәт көне эшләделәр. Укучылар күп кенә колхозларда һәм совхозларда төп авыл хуҗалыгы эшләрен башкардылар.

Хәзерге көндә безнең бурыч балалар арасында күтәрелгән бу политик активлыкны ныгытудан һәм тагын да үстерүдән гыйбарәт. Сугыш вакыты балаларга тәрбия бирү эшләрен мәктәп эчендә генә түгел, бәлки балаларның өйләрендә дә көчәйтүне таләп итә.

Күп кенә мәктәпләр үз алларына куелган бурычларны яхшы хәл итәләр. Казан шәһәренең Сталин районындагы 12 нче номерлы мәктәп бу өлкәдә гүзәл үрнәкләр күрсәтте. Мәктәп директоры Хәмитов һәм уку-укыту бүлеге мөдире Нурмөхәметова иптәшләрнең активлыгы белән бу мәктәп янында 100 балалык производство мастерское оештырылды. Балалар эшли торган бу скорняк-мех мастерское фронт өчен булган заданнене 140 процент итеп үтәде. Бу мастерскойга 1 нче кварталда 100 мең сумлык продукция эшләп чыгарырга задание бирелгән иде, ә мастерской бер ай эчендә 50 мең сумлык продукция җитештерде. Мастерскойда эшләү балаларның мәктәптә укуларына кимчелек китерми. Алар мастерскойда көнгә 2 сәгать ярым эшлиләр. Балалар мастерскойда хезмәткә өйрәнәләр. Мастерскойга һәм мәктәпкә үз вакытында киләләр. Игътибарга алынырлык сәбәпләрдән башка эшкә һәм укуга килмичә калган бер генә укучы да юк. Уку елының 2 нче чирегендә бу мәктәптә өлгереш, беренче чирек белән чагыштырганда 18 процент күтәрелде. Укучыларның күбесе мастерскойда эшли торган 7 нче һәм 8 нче классларда өлгереш тагын да югарырак.

Моның сере нәрсәдә соң? Шунда: балалар фронт заказларын үтәгәндә үзләрен сугышта катнашкан кебек хис итәләр. Алар фашистларга каршы көрәшүче бөтен ил тормышы белән яшиләр. Шунлыктан мәктәптә дә, мастерскойда да эш яхшы бара.

Казан шәһәренең башка күп кенә мәктәпләрендә дә шундый ук мастерскойлар төзелде. Бу тәҗрибәне Татарстанның барлык мәктәпләрендә дә эшкә ашырырга кирәк.

Безнең балаларыбыз совет халкының үткәндәге героик тормышын, сугыш тарихын, ватан сугышы героикасын өйрәнү белән, шулай ук хәрби эшкә өйрәнү белән бик нык кызыксыналар. Комсомол һәм пионер оешмалары, педагоглар ярдәме белән, балаларның бу сорауларын тулысынча канәгатьләндерергә тиешләр. Мәктәпләрдә укучы балаларны хәрби эшкә өйрәтү турында СССР Совнаркомы карары уңае белән безнең мәктәпләребез Кызыл Армия өчен командирлар әзерли торган урын булып әверелделәр. Мәктәпләрдәге комсомол оешмалары бу эшкә якыннан торып катнашырга, хәрби җитәкчеләргә ярдәм күрсәтергә, балаларны сугыш техникасы белән таныштырырга тиешләр.

Казан шәһәренең 24 нче мәктәбендәге комсомол оешмасы (ВЛКСМ комитеты секретаре иптәш Девятов) әһәмиятле тәҗрибә үткәрә. Анда хәрби тарихи темаларга укучыларның конференцияләре оештырыла. Бу конференцияләрдә докладлар белән укучылар үзләре чыгыш ясыйлар. Бер конференциядә укучылар «Совет халкының үткәндәге героик тормышы», «1812 нче елгы ватан сугышында партизаннар хәрәкәте», «1918—1920 нче еллардагы гражданнар сугышы», «Немец-фашист басып алучыларга каршы бөек ватан сугышында партизаннар көрәше» дигән темаларга докладлар ясадылар. Укучылар аларның докладларын зур кызыксыну белән тыңладылар.

Казан шәһәренең 19 нчы мәктәбендә хәрби диңгез флоты тарихы турында һәм артиллерия тарихы турында конференцияләр үткәрүгә әзерлек бара. Республикабызның башка күп кенә мәктәпләрендә дә шундый конференцияләр булып үтте. Комсомол оешмалары бу гүзәл тәҗрибәне барлык мәктәпләргә күчерергә тиешләр.

Мәктәпләрдә тәрбия эшендә пионер оешмалары гаять зур роль уйныйлар. Хәрби эшне өйрәнүдә, тимер командаларының эшләрен җәелдерүдә вожатыйлар балаларга якыннан торып булышлык күрсәтергә тиешләр.

Күп кенә пионер оешмалары бу өлкәдә яхшы тына эшләп киләләр. Бауман районындагы 3 нче номерлы дружинаның 2 нче отряды пионерлары фронтовик хатыны иптәш Волковага ярдәм күрсәткәннәр. Алар аның балаларын аяк киемнәре белән тәэмин итүгә булышлык күрсәткәннәр, бер баласын яслегә урнаштырганнар. Волкова эшкә киткән вакытта пионерлар аның бүлмәсен җыештыралар һәм башкача булышлык күрсәтәләр.

Кызыл Армия районының Иске Ромашкино тулы булмаган урта мәктәпнең пионер дружинасы да яхшы эшли. Һәрбер пионерга кыш көне эшләргә задание бирелгән. Пионерлар терлекчелек фермасындагы 45 баш яшь терлекне шефлыкка алганнар. Алар пионерларның бөтен Союз күләмендәге якшәмбе өмәсендә 50 гектар саламны эскертләгәннәр.

Ләкин гомумән алганда пионерлар арасында эшләү җитәрлек түгел әле. Күп кенә мәктәпләрдә өлкән вожатыйлар юк. Кайбер өлкән вожатыйлар кирәгенчә эшләмиләр. Пионер дружиналарының эшенә укытучыларны, комсомолецларны һәм класс җитәкчеләрен киң күләмдә тартырга кирәк. Дружиналар янында түгәрәкләр оештырылырга тиеш. Һәрбер отрядның, һәрбер дружинаның шахмат буенча, кышкы спортның барлык төрләре буенча үзләренең чемпионнары булсын.

Педагогларның, иң беренче чиратта укытучы-комсомолецларның бурычы бу эшләрдә зур инициатива күрсәтүдән, комсомолга һәм балалар коллективының үзәге булган дружина штабларына таянып эшләүдән гыйбарәт. Яшь гражданнар арасында тәрбия эшләре хәзер аеруча көчәйтелергә тиеш.

Ф. АБДУЛЛИН,

ВЛКСМ Татарстан Өлкә Комитетының мәктәпләр буенча секретаре.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕКНЕ БАРЛЫК ТАРМАКЛАР БУЕНЧА КИҢ ҖӘЕЛДЕРЕРГӘ!



Н-че завод дошманнан алынган орудиеләрне төзәтә. Рәсемдә: җыю цехында. Эре калибрлы трофей орудиене буяу. ТАСС фотохроникасы.

Кызыл Армиягә—танклар һәм самолетлар!

Октябрь районы колхозчылары җавабы

(ТЕЛЕГРАФ БУЕНЧА)

Бу көн колхозчылар өчен зур бәйрәм булды. Бөек полководец иптәш Сталин аларга туганнарча сәлам һәм Кызыл Арми янең рәхмәтен җибәрде. Даһи юлбашчы, танклар колоннасы төзүгә 2.538.000 сум акча, Кызыл Армия фондына 12.566 пот һәм промышленность эшчеләренә 4.000 пот ашлык тапшырулары өчен колхозчыларны котлады. Шушы уңай белән районда тантаналы митинг булды.

Митинг буласы көнне иртәдән үк җанлылык сизелә иде. Районның төрле почмакларыннан ашлык, ит һәм башка продуктлар төялгән кызыл олаулар агыла башлады. Сталин исемендәге колхозның кызыл олавын авыл советы председателе иптәш Дементьева алып килде. Колхозчылар митингка 480 пот ашлык, 100.000 сум акча җибәргәннәр. Беренче олауга «дошманны тар-мар итү өчен» дип язылган кызыл флаг куелган.

Нәкъ көндезге ике сәгатьтә тимер юлчылар клубында митинг ачылды: Митингны ачучы иптәшнең Сталин дигән сүзен ишетү белән делегатлар барысы да урыннарыннан торалар. Көчле «ура» тавышы яңгырый. Беренче сүзне Урта Камышлы авыл советы председателе иптәш Андреев ала: Аның сүзләре кыска, ләкин колхозчылар тарафыннан җибәрелгән бүләкләр бик зур: зур капчыкка тутырылган—400.000 сум акча.

— Бу безнең колхозчыларның бүләге. Алар иртәгә тагын 400.000 сум җибәрергә булдылар,—ди иптәш Андреев.

Аның артыннан шундый ук капчык күтәреп Илюткин авыл советы председателе иптәш Воронцов чыга. Ул 200.000 сум акча, 460 пот ашлык, 60 сарык китергән. Шулай итеп колхоз патриотлары Кызыл Армиягә үзләренең сәламнәрен әйтәләр һәм бүләкләрен тапшыралар. Районда бер көн эчендә генә дә сугышчан самолетлар төзүгә 1.709.000 сум акча тупланды. Кызыл Армия фондына. планнан тыш. 4.400 пот ашлык, 1.842 пот ит, 400 тавык, 69 киез итек һәм башка җылы киемнәр килде.

САМСОНОВ.

ИПТӘШ СТАЛИНГА РАПОРТ БИРЕЛДЕ

Н-че заводның эшчеләре, эшче хатын-кызлары, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре һөҗүм итеп баручы батыр Кызыл Армиябезгә һәрьяклап ярдәм итү өчен бер нәрсәне дә кызганмыйлар.

—Безнең улларыбыз, ирләребез, туганнарыбыз фронтта дошманны мәрхәмәтсез кыралар, совет җирләрен гитлерчы кабахәтләрдән чистарталар. Сөекле Кызыл Армиябезнең һөҗүм итү көчен тагын да арттыру өчен без өстәмә танк колонналары, самолет эскадрильялары төзүгә үзебезнең саклык акчаларыбызны шатланып бирәбез,—диләр Романова, Ибәтуллина, Садовникова һ. б. иптәшләр.

Цех начальнигы Амелин, заводның баш инженеры Кадышев иптәшләр 1.000 әр сум, механиклардан Орлов, Абдерәшитов, Якимов иптәшләр 500 әр сум акча кертте-ләр һ. б.

Завод күләмендә хәзер 100 мең сум акча җыелды инде. Коллектив бу турыда иптәш Сталинга махсус рапорт-телеграмма җибәрде.

500 мең сумлык бүләк

Завком председателе урынбасары иптәш Иванов булган завод коллективы Кызыл Армиянең 25 еллыгына батыр сугышчыларыбыз өчен 500 мең сумлык бүләкләр әзерләргә булды. Бер үк вакытта самолетлар эскадрильясы төзү буенча да акчалар җыю башланды. Акатов һәм Брук иптәшләр эскадрилья төзүгә январь ае өчен булган барлык хезмәт хакларын бирделәр. Заводның директоры һәм партком секретаре батыр сугышчыларга бүләккә—500 әр сум, эскадрилья төзүгә—берәр мең сум акча бирделәр.

Акчалар җыю дәвам итә.

ФӘН НИ РАБОТНИКЛАРДАН

Самолетлар эскадрильясы төзү фондына акча туплауда СССР фәннәр академиясе работниклары актив катнашалар. Академик Виноградов самолетлар эскадрильясы төзүгә 85.000 сум акча кертте. Академик Орбели һәм Тарле иптәшләр 25.000 әр сум тапшырдылар. Академик Кржижановский 22.500 һәм академик Абрикосов 21.000 сум акча керттеләр.

Казан психиатрия больницасы работниклары «Медицинский работник» исемле самолетлар эскадрильясы төзү фондына 80.000 сум акча керттеләр.

ӘЗЕРЛЕК ТӨГӘЛЛӘНӘ

(Шөгер районы, „Кызыл шушма“ колхозы председателе иптәш С. КӘРИМОВ белән беседа)

Хәзер безнең колхозда язгы чәчүгә әзерлек эше бөтен киңлегенә җәелдерелде. Тимерчелектә ремонт эшләре тәүлек буена туктаусыз дәвам итә. Тимерчеләрдән Юнус Галиев, Сәет Галиев иптәшләр янына һәрбер бригададан тагын икешәр кешене ремонт эшенә бирелеттек. Беренче бригаданың барлык сабаннары, культиваторлары, тырмалары ремонтланып бетте диярлек. Икенче бригада да ремонтны шушы көннәрдә тәмамлый.

Хатын-кызларның күбесе чәчүлек орлык чистартуда эшлиләр. 208 центнер бодай, 100 центнер солы, 94 центнер борчак, 16 центнер ясмык, 27 центнер карабодай, 6 центнер киндер орлыгы, 39 центнер вика, 148 килограмм шикәр чөгендере орлыгы, 4 центнер көнбагыш орлыгы чистартылып, амбарга салып куелды. 127 центнер бәрәңге орлыгыбыз бар.

Орлыкларның тишелеп чыгышы тикшерелә. Бодай һәм солы орлыгының тишелеп чыгышы 98—99 процент. Орлык чистартуда М. Ихсанова, С. Җамалиева, Р. Сабирова иптәшләр аеруча зур тырышлык белән эшлиләр. Алар триерлауда норманы 200—250 процентка кадәр үтиләр.

Колхозчылар җирле ашламалар әзерләүгә, агротехника чараларын үткәрүгә зур игътибар бирәләр. Бигрәк тә хатын-кызлар көл һәм кош тизәге җыюда актив катнашалар. Хәзер безнең 300 пот җыеп куелган көлебез, шулай ук шактый санда кош тизәге бар.

Бездә, быел үткән елгы кебек үк, сөрү һәм тырмалау эшләрен күбрәк хатын-кызлар башкарачак. Үткән ел бу эштә эшләгән Җамалиева, Галимова, Заһретдинова иптәшләр һәрберсе бу эшләрнең техникасы белән таныштыру өчен икешәр хатын-кызны шефка алып, аларны өйрәтәләр.

Колхозыбызда агротехника түгәрәге эшли башлады. Биредә колхозчылар җирле ашламалар әзерләү, орлыкларны чистарту, җирне эшкәртү һәм башка турыда лекцияләр тыңлыйлар.

Язгы чәчү вакытында ат көченең нинди әһәмияткә ия булуы билгеле. Без хәзер эш атларын яхшы итеп тәрбияләүгә зур әһәмият бирәбез. Җәйге эш вакытында күп җигелгән һәм эшләгән атлар аерым тәрбиягә куелдылар.

Язгы чәчүгә әзерлекне 1 нче февральгә тулысы белән тәмамлау өчен көрәшәбез. Игеннәрне урып-җыю вакытында сбруйлар, инвентарьлар аеруча күп кирәк була. Менә шуны искә алып, бригадир Галиев һәм Шәфиков иптәшләр урып-җыю вакыты өчен дә сбруйларны һәм төрле авыл хуҗалыгы инвентарьларын хәзердән үк җитәрлек итеп әзерләү эшенә керештеләр. Алар үз бригадаларыннан М. Ябин, Н. Галимов иптәшләр җитәкчелегендә сбруйлар әзерләү өчен махсус бригада оештырдылар. Бу бригада 30 стан тәгәрмәче, 30 арба, көлтә арбалары, дилбегәләр, арканнар, йөгәннәр әзерләп куйды инде. Сүстән бау ишү оештырдык.

ПЛАН АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

Дуңгыз асраучылык фермаларының елдан-ел арта баруы илебезне ит продуктлары белән тәэмин итүне җиңеләйтә. Шуның өчен дә Буа районында, соңгы елларда бу эшкә аеруча нык әһәмият бирелә. 1942 нче елда дуңгыз асраучылык планы шактый күп арттырып үтәлде. Моннан бер ел элек кенә дуңгыз асраучылык фермасы бары 13 колхозда гына иде. Хәзер 39 колхозда дуңгызлар үрчетелә.

Күп кенә колхозлар дуңгыз үрчетү буенча зур гына уңышларга ирештеләр. «Победитель» колхозында дуңгызларның саны ике тапкыр артты. «Маяк» колхозында да моннан бер ел элек 3 кенә дуңгыз бар иде. Хәзер биредә дуңгызларның саны 20 башка җиткерелде. Калинин исемендәге колхозда да дуңгыз асраучылык фермасы 4 тапкырга артты.

Г. ГАЯЗОВА.

Еллык план ни өчен үтәлмәде?

Ватан сугышы чорында хезмәт ияләрен һәм колхозчылар массасын кирәкле товарлар һәм бигрәк тә киң куллану товарлары белән тәэмин итү—мактаулы һәм җаваплы эш. Потребкооперация работниклары товар әйләнеше, киң куллану товарлары җитештерү һәм авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү планын төгәл үтәү өчен нык көрәшергә тиешләр.

Ләкин Чистай райпотребкооперациясе работниклары 1942 нче елда югарыда күрсәтелгән бурычларны үтәүгә гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар караганнар. Товар әйләнешенең еллык планы 81 процентка, киң куллану товарлары җитештерү планы 67 процентка, бәрәңге әзерләү планы 37 процентка һәм яшелчә әзерләү планы 60 процентка гына үтәлгән.

Райпотребкооперация, шулай ук, районда металл җыю эшләрен дә башкарырга тиеш. Районда кирәксез, ташландык металлны һәрбер колхозда табарга мөмкин. Ләкин райпотребкооперация председателе Мөхетдинов үзенә йөкләтелгән бу эшкә дә игътибар бирмәгән, гамьсез караган: план 31 процентка гына үтәлгән.

Июль аенда райпотребкооперациягә, киң куллану товарлары җитештерү буенча, Татсоюз тарафыннан план җибәрелә. Ләкин Мөхетдинов бу эш белән 15 нче ноябрьдә гына шөгыльләнергә керешкән. План буенча киез итек басу цехы оештырылып, 4 нче кварталда 600 пар эшләнергә тиеш булса, ул 120 пар гына эшләнгән. Аларның да сыйфаты чиктән тыш начар.

Кайбер сельпо мөдирләре еллык товар әйләнеше планын үтәүгә бигрәк тә игътибар бирмәгәннәр. Мәсәлән, Тат. Баганалы авылы сельпосы еллык планны 67 процентка, авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү планын 30 процентка гына үтәгән. Мехчимал әзерләү планы нибары 13 процентка үтәлгән, ә киң куллану товарлары җитештерү планы бер процентка да үтәлмәгән. Бу авылда чиләк, тагарак ясаучы Әбдәхимов кебек мастерлар булса да, сельпо председателе иптәш Сафина аларны оештыруга игътибар бирмәгән. Мөслим, Иске Бигәнәй сельполары еллык планның үтәлешен бөтен төр буенча да хурлыклы рәвештә өзгәннәр.

План буенча райпотребсоюз 40 баш дуңгыз, 25 баш сарык һәм 2 сыер булдырырга тиеш иде. Ләкин бу да үтәлмәгән. Анда хәзер ике елдан бирле балаламый торган бер дуңгыздан башка бер нәрсә дә юк.

Сәүдә работниклары арасында ярыш оештырылмаган. Наратлы авылы сельпо председателе Золотарев бүлекчәдә эшләүчеләр белән ел буена бер генә беседа да үткәрмәгән. Шуңар күрә монда план да үтәлмәгән.

Планнарның үтәлешен ачыктан-ачык өзүче эшлексез җитәкчеләргә карата район оешмалары да бернинди дә чара күрмәгәннәр. Тик Мөхетдиновны урыннан алу белән генә чикләнгәннәр.

Ш. ШАКИРОВ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

19 нчы ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

19 нчы январьда **Воронеж фронты** гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, **Валуйки** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, **Уразово** шәһәрен һәм тимер юл узелын, район үзәкләреннән **Шаталовканы** һәм **Вейделевканы** алдылар.

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре кискен атака нәтиҗәсендә **Каменск** шәһәрен, район үзәге һәм зур тимер юл станциясе **Белая Калитваны** һәм халык яши торган күп кенә зур пунктларны алдылар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр **Петровское** шәһәрен һәм тимер юл узелын, **Спицевское** район үзәген, тимер юл станцияләреннән **Спицевканы, Кугутыны, Кианны, Дворцовыйны**, халык яши торган зур пунктлардан **Донская Балканы, Сухая Буйволаны, Георгиевскаяны, Рощинскийны, Адыче-Хабльне** алдылар.

* * *

18 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 15 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 8 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар, ике батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр немец фашистларының чолганып алынган гаскәрләрен кыруны дәвам иттерделәр. Шәһәрдән көнбатыштарак безнең частьлар алга киттеләр һәм 800 гитлерчыны юк иттеләр. 329 кеше плен алынды. 9 самолет, 12 танк һәм бронемашина, берничә йөз автомашина, 244 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Шәһәрдә безнең штурм отрядлары дошманның ныгытылган позицияләрен алдылар.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Орловскаядан көньяк-көнбатыштарак булган районда халык яши торган бер зур пункт өчен бик каты сугышлар бара. Икенче бер участокта безнең частьлар дошманның чолганып алынган группасын юк итү буенча сугышлар алып баралар.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер районда дошман үзенең чолганып калган гарнизонына ярдәмгә бик күп пехота һәм танклар җибәрде. Безнең частьлар дошманның берничә контратакасын кире кайтардылар. Каты сугышларда немецларның бер полк пехотасы кырып ташланды. Миллерово шәһәрендә гитлерчылар үзләренең яраланган 500 солдатларын язмыш иркенә ташлап киткәннәр. Шәһәр территориясендә дошманның 3.000 нән артык үле гәүдәләре калды. 950 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. 11 танк, 17 самолет, 58 орудие, 840 автомашина, 10 азык склады, 2 әчемлек склады, бер кием склады, төрле йөкләр төялгән тимер юл составлары, ягулык тутырылган 1.000 мичкә һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелде.

Воронеж фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Острогожскида чолганып калган немецлар гарнизоны шәһәрдән чыгу өчен берничә тапкыр бөтен көчен биреп тырышып карады. Гитлерчыларның барлык контратакалары алар өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. Халык яши торган Постоялый пунктында безнең хәрәкәттәге частьларыбыз ике сәгать сугышканнан соң 5.000 итальян солдатын һәм фоицерын плен алдылар. Халык яши торган Алексеевка пункты районында безнең подразделениеләр итальяннарның бер зур автоколоннасына атака ясадылар. Итальяннар каты каршылык күрсәтмәделәр һәм озакламый бирелделәр. 700 автомашина кулга төшерелде. Совет сугышчылары шул машиналарга утырып, дошманны куып баруларында дәвам иттеләр.

* * *

Ладога күленнән көньяктарак безнең гаскәрләр бик каты һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары сугыша-сугыша алга киттеләр һәм дошманның сугыш припаслары һәм азык тутырылган 4 складын, 20 автомашинасын һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Иптәш Трубачев командалыгындагы часть, немецларның Шлиссельбург группировкасын тар-мар итеп, күп кешеләрне, шул исәптән немецлар батальоны командирын плен алды.

* * *

Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар халык яши торган берничә пунктны немецлардан чистарттылар. Иптәш Максимов командалыгындагы сугышчылар дошманның контратакасын кире кайтардылар, 300 гитлерчыны кырдылар һәм немецларның 7 танкысын яндырдылар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр, Черкесск шәһәрен алып, Кубань елгасы аркылы кичтеләр. Дошман каты каршылык күрсәтә. Совет частьлары, дошманның җанлы көчләрен һәм техникасын юк итеп, алга таба баралар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Черкесск шәһәрендә түбәндәге трофейлар кулга төшерелде: 54 орудие, 195 пулемет, 48 миномет, шул исәптән алты кешәле 22 миномет, 700 дән артык винтовка, 5 радиостанция, 2 сугыш припаслары склады, документлар белән бергә штаб машинасы, полк байрагы һәм башка төрле сугыш милекләре.

* * *

Смоленск партизаннарының бер отряды немецларның бер аэродромына һөҗүм иткән. Совет патриотлары дошманның пикировать итүче 6 бомбардировщигын, 2 истребителен, 2 разведчигын һәм 4 транспорт самолетын юк иткәннәр. Очучылар составыннан һәм аэродром командасыннан 62 немец солдаты һәм офицеры үтерелгән һәм яралангап.

ГЫЙРАК ХӨКҮМӘТЕ ГЕРМАНИЯГӘ, ИТАЛИЯГӘ ҺӘМ ЯПОНИЯГӘ СУГЫШ ИГЪЛАН ИТКӘН

ЛОНДОН. (ТАСС). **Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Гыйрак хөкүмәте Германия, Италия һәм Япония белән Гыйракның сугыш хәлендә булганлыгын игълан иткән.**

Гыйрак хөкүмәтенең белдерүендә күрсәтелгәнчә, күчәр державалар озак вакыттан бирле Гыйракка карата дошманлык позициясендә торганнар, ә аларның агентлары Гыйракның законлы хөкүмәтен юк итүгә һәм Гыйрак хөкүмәтенә басым ясарга юнәлдерелгән эшләрне тормышка ашырганнар. Күчәр державалар Гыйракка каршы һәм аның интересларына каршы радио аркылы пропаганда алып барганнар, Гыйрак халкы арасында фикер башкалыгы һәм аерылышу тудырырга омтылганнар, төрле ялган хәбәрләр тарату юлы белән җәмәгать тәртибен бозарга һәм илнең куркынычсызлыгын җимерергә маташканнар. Күчәр державаларының радиостанцияләре Гыйракның король йорты адресына карата хурлап сөйләргә юл куйганнар һәм илдә конституция режимын үзгәртергә маташучы кайбер җинаятьче элементларга булышлык күрсәткәннәр. Шул уңай белән һәм, аерым алганда, Гыйракның һәм гомумән гарәбләрнең берләшкән милләтләр декларациясенә кушылу белән кызыксынуларыннан чыгып, «Гыйрак хөкүмәте Германия һәм Италия белән, шулай ук Гыйракта Германия планнарын тормышка ашыруга актив булышлык күрсәткән Япония белән сугыш хәлендә икәнлеген игълан итәргә карар биргән».

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

Кытайның атаклы очучыларыннан капитан И-Фу-Энь Лос-Анжелостан (АКШ) Африка аркылы Кытайның Ченду шәһәренә очышны уңышлы рәвештә тәмам иткән. Ул Атлантик диңгез аркылы Кытайга кадәр очып килгән беренче Кытай очучысы.

* * *

Румыния хөкүмәте гражданнар халкына тимер юл транспортыннан файдалануны тыйган.

* * *

Быел АКШ та һәм Канадада 300-400 мең тонна ясалма каучук әзерләп чыгарырга билгеләнгән. 1944 нче елда ясалма каучук эшләү 1 миллион тоннага җиткереләчәк.

* * *

Чилидагы эшчеләр конфедерациясе Чили белән күчәр державалар арасындагы мөнасәбәтләрне өзүне таләп итеп массовый митинглар оештырган.

* * *

Немецлар үзләренең яралыларын урнаштыру өчен Даниядәге бик күп больница һәм мәктәп биналарына реквизиция ясаганнар. (ТАСС).

ФРАНЦИЯ КОМПАРТИЯСЕНЕҢ ФРАНЦИЯНЕ АЗАТ ИТҮ ӨЧЕН КӨРӘШЕ

ЛОНДОН, 17 январь. (ТАСС). Сугышучы Франциянең Милли Комитетының хәбәр итүенә караганда, Лондонга Франция парламенты члены һәм Франция коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты члены Фернан Гренье килгән. Ул 1940 нчы елда немецлар тарафыннан кулга алынган һәм концлагерьга ябылган булган. Гренье аннан качып киткән. Франциянең коммунистлар партиясе Греньега, Франция коммунистлар партиясенең Сугышучы Франция хәрәкәтенә кушылганлыгы турында де Голльга һәм Милли Комитетка рәсми белдерү тапшырырга кушкан. Милли Комитетның белдерүендә әйтелүенчә, Коммунистлар партиясенең кушылуы белән Франциядәге барлык партияләрнең Милли Комитет тирәсенә тупланулары төгәлләнә. Франциянең барлык партияләре, үзләренең политик фикерләрендә үзгәлекләр булуга да карамастан, Франциянең дошманнарына каршы кулга кул тотынып сугышалар.

Гренье Лондонда матбугат вәкилләре алдында чыгыш ясаган. Аның әйтүенә караганда, Франциянең коммунистлар партиясе, Франциядә немец оккупантлар тарафыннан каты террор режимы үткәрелүгә дә карамастан, дошманга оешкан рәвештә каршылык күрсәтүне эшкә ашыра. Франциядә яшерен рәвештә компартия Үзәк Комитеты органы «Юманите» газетасы һәм аннан башка ике газета чыгарыла. «Юманите» газетасының 200 номеры чыккан инде. Шуның өстенә 1942 нче елда 100.000 данә төрле брошюралар басып чыгарылган. Яшерен рәвештә чыгарылган барлык матбугатның гомуми саны 6 миллион данәгә җитә.

Греньеның әйтүенә караганда, компартия де Голль ягындагы кешеләргә булышлык күрсәтеп, дошманга каршылык күрсәтүне оештыруда катнашкан, Германиягә каршы саботаж һәм партизаннар хәрәкәтен оештырган. Танклар һәм йөк машиналары эшли торган заводларда, шулай ук консерва заводларында саботаж һәм диверсияләр үткәрелә. Дижон шәһәрендә Франция патриотлары 70 паровозны бозганнар. Оккупантларга каршылык күрсәтүдә Франциядәге халыкларның барлык катлавы катнаша. Бу эштә Франция интеллигенциясенең роле бик зур. Профессорлар һәм студентлар немецларга каршы бердәм рәвештә чыгыш ясыйлар. Профессорлар профсоюз членнары арасында яшерен газеталар таратуны оештырганнар. Франциянең крестьяннары Германиягә барудан баш тартучы эшчеләргә һәрьяклап ярдәм күрсәтәләр.

Греньеның әйтүенә караганда, оккупантларга карата нәфрәт тойгысы көннән-көн ныгый бара. Оккупантлар террор юлы белән Франция халкының каршылыгын җимерергә маташалар. Франция капитуляция ясаган вакыттан бирле Виши властьлары һәм оккупантлар 10.000 гә якын французны атып үтергәннәр һәм төрмәләргә ябып газаплаганнар. Хәзерге көндә 40-50 меңгә якын французлар тоткынлыкта торалар. Виши хөкүмәте һәм немецлар бөтен илдә ачлык режимы керткәннәр. Эшче поселокларында мәктәп яшендәге балаларның 80 проценты ач тору сәбәпле түберкулез белән авырып үлү куркынычы алдында тора.

Төньяк Африкада сугыш хәрәкәтләре

ЛОНДОН, 18 январь. (ТАСС). **Рәсми хәбәрләргә караганда, Роммель үзенең транспортларын Мисуратадан һәм Триполидан көнбатышка җибәрә башлаган. Аның гаскәрләре Туниска чигенәләр булырга кирәк дип уйлыйлар.**

Эль-Аламейн янында сугышканга кадәр Роммельның 11 дивизия гаскәре, 600 танкысы һәм шактый күп авиация көчләре булган. Ноябрь урталарына күчәр державалар Африкадагы армияләрендәге кешеләр составының 4 тән өч өлешен, танкларның 80 процентын, 6000 нән артык орудиеләрен, 10.000 автомашиналарын һәм 697 самолетларын югалтканнар. Ливия аркылы чигенгән вакытта Роммель гаскәрләренә беркадәр корал һәм өстәмә гаскәр алынган. Ләкин хәзерге көндә Роммель кулында Эль-Аламейн янында булган сугыш вакытындагыга караганда кешеләр составының тик яртысы һәм танкларның дүрттән бер өлеше генә бар.

Роммельгә өстәмә көчләр алырга мөмкин булган Тунисга дошманның 70.000 гаскәре бар, ләкин аның танклары һәм артиллериясе җитми. Күчәр державаларының Тунистагы һава көчләрендә 200 самолет исәпләнә.

Хәзерге вакытта дошман 5 порттан—Бизерта, Тунис, Сфакс, Сус һәм Габес портларыннан файдалана ала. Шунлыктан Триполины югалту дошман өчен бик үк зур зарар китермәс иде, ләкин бу гаваньның алынуы инглизләр өчен зур әһәмиятле урынны тота. Англиянең 8 нче армиясе коммуникацияләре Бенгазига кадәр 500 мильгә сузылган. Триполиның алынуы транспортка, ягулыкка һәм вакытка зур экономия ясауга китерәчәк.

Эль-Аламейн янында 8 нче армия 13.600 кешесен югалткан. Аның танкларын һәм артиллериясен югалтуы дошманның югалтуына караганда шактый ким. Ләкин 8 нче армиянең киләчәктәге хәрәкәтләрен тәэмин итү өчен сәхра районында яңа база оештырырга кирәк.

Триполи-Тунис-Сицилия өчпочмагының көнбатыш өлешендә базалар булмау сәбәпле союзникларга үзләренең һөҗүмнәрен кичектереп торырга туры килгән, немецлар шуннан файдаланып, Тунисның төньяк өлешенә кыска юллардан гаскәр китерә алганнар. Хәзерге көндә Англиянең беренче армиясе үзенең коммуникацияләрен яхшырта һәм тәэминат эшләрен оештыра.

Франциянең 50.000 кешедән торган гаскәрләре Туниста фронтның үзәк участогын кулларында тоталар.

ЛОНДОН, 18 январь. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, Триполитаниядә соңгы өч көнге сугышларда Англиянең 8 нче армиясе 50 миль чамасы алга барган һәм хәзер Мисуратадан 60 миль көньяктарак тора.

Авиация көнбатышка таба бара торган гаскәрләргә зур ярдәм күрсәтә һәм дошманга шактый зур зарар китерә, аны бомбага тота һәм пулеметлардан ата.

16 нчы январьда Сицилия атавына бик каты һөҗүм ясалган.

8 нче армия алга хәрәкәт иткәннән соң сахрадан бөтенләй чыккан булырга кирәк дип уйлыйлар. Хәзерге көндә бу армиягә шактый күп халык яши торган пунктлар булган, игенне яхшы үндыра торган территория аркылы барырга кирәк булачак.

ЛОНДОН, 18 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Сугышучы Франция гаскәрләре генерал Леклерк командалыгында Чад күле янындагы базаларыннан 1.500 миль араны үтеп, Тунисның көньяк өлешендә Франция гаскәрләре белән һәм Ливиядә Англиянең 8 нче армиясе белән кушылганнар.

БЕРЛИНГА АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ЯҢА ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 18 январь. (ТАСС). Рәсми хәбәргә караганда, 18 нче январьга каршы төндә Англия авиациясе Берлинга яңа һөҗүм ясаган.

17 нче январьга каршы төндә Англиянең 4 әр моторлы бомбардировщиклары тарафыннан Берлинга ясалган һөҗүм бер сәгатькә якын дәвам иткән. Шәһәргә 10 меңнәрчә яндыргыч бомбалар һәм бик күп фугаслы бомбалар, шул исәптән 3 тонна ярымнан да авыррак бомбалар ташланган. Очучылар шәһәрдән 200 километр ераклыкка очып киткәннән соң да шәһәр өстендәге ялкынны күргәннәр.

17 нче январьда көндез Англия авиациясе Төньяк Франция һәм Голландия өстендә операцияләр алып барган, аларда дошманның корабльләренә һәм тимер юл объектларына атакалар ясалган.

Авыр бомбардировщикларның эре берләшмәләре 18 нче январьга каршы төндә Берлинга икенче тапкыр һөҗүм ясаган вакытта шәһәргә яңадан бик күп бомбалар ташланган. Бомбага тоту тәмам булган вакытта Берлинда бик зур янгыннар чыккан. Англия самолетлары дошман истребительләре белән берничә тапкыр сугышканнар. Бу операцияләрдән 22 бомбардировщик үз базаларына кайтмаганнар.

Кичә Германия самолетларының бер кечкенә группасы Лондонга һөҗүм итәргә маташкан. Шәһәр өстенә берничә яндыргыч бомба һәм шәһәр бистәләренә берничә фугаслы бомба ташланган.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

ПФ 618 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 122